# Сират күпре була ул көн

Запись Масгуды Шамсутдиновой



Сират күпре була ул көн, кылдан нечкә, кылычдин үткен,
Асты тулы ут һәм төтен, һәркем андыйн үтәр шул көн.
Кеми үтәр асыл кош, дип, кеми үтәр искән җил, дип,
Кеми аяклары таеп Җәһәннәмгә китәр ул көн.
Тәүбә илә үткән коллар ул күпердин үтәр ул көн,
Җәннәт булыр урыннары, хурлар каршы алыр көн.

©